**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле авылы торак пунктында гражданнар җыены**

# КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре №6

2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Керкәле авыл җирлегенең Керкәле авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлеге Керкәле торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Керкәле авыл җирлеге Керкәле авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балачактан инвалидлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының тол хатыннары; көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1) торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

- янгын гидрантын урнаштыру;

2) торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру:

- Заря урамында Сабантуй үткәрү мәйданчыгын төзекләндерү (майдан периметры буенча эскәмияләр урнаштыру);

3) Җирлек территориясен күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы итеп, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү:

Керкәле торак пунктында механикалаштырылган һәм кул белән үлән чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу) ;

Тактакуш урамындагы иске агачларны, куакларны кисү;

4) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Керкәле торак пунктыВахитов урамындагы грунт-вак таш җәелгән юлларны ремонтлау;

- Керкәле торак пунктында юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле авылы, Совет урамы, 93 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.И.Бигманов